**Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение «Высокогорский детский сад «Солнышко» Высокогорского муниципального района Республики Татарстан**



# АБДУЛЛА АЛИШ «КОЙРЫКЛАР»

**Максат:** Татар халык иҗаты әсәрләрен өйрәнүне дәвам итү.

Ярдәмчел булырга, бер-береңә булышырга өйрәтү.

Әкиятне рольләргә бүлеп, сүзләрне дөрес әйтеп уйнау.

Балаларда  артистлык сәләтен үстерү.

**Сәхнә бизәлеше:** Җиһазлау:

Урман күренеше өчен агачлар.

Төрле җәнлекләр костюмнары.

Биючеләр өчен татар күлмәкләре.

Урман күренеше

Койрыклар,

**Катнашалар:**

Алып баручы –Самир,

Куян- Ясмина,

Саескан – Рахим,

Аю – Карим,

Бүре – Илназ,

Төлке – Даяна,

Эт – Айнур,

Песи-Амелия.

“Койрыклар”

(А.Алишның “Койрыклар” әкиятенә сәхнәләштерелгән күренеш)

*Бала автор:*

Борын - борын заманда,

Әле мин тумаганда

Урмандагы хайваннарның

Койрыксыз вакытында...

Яшәгәннәр барысы бергә

Дус-тату торганнар алар,

Койрыклары булмаса да,

Күңелсез булмаганнар,

Матур итеп, тату яшәп,

Бергәләп уйнаганнар.

*(Бу вакытта җәнлекләр һәркайсы үз эше белән)*

Беркөн шулай саескан

Көне буе урманда

Хәбәр тататып йөргән.

*Саескан:*

Хәерле көн сезгә дуслар,

Бер яңалык җиткерәм,

Кояш чыккач, томан беткәч,

Урмандагы карт имән янына

Койрык сайларга килегез,

Үзегезгә килешле койрыкны алып та китәрсез.

*(Хайваннар барсы бергә)* Нәрсә соң ул койрык?

*Төлке уртага чыгып:* Ярый, ярый, өләшәләр икән барып карыйк, карарбыз, яраклымы, юкмы...Нәрсә икәнен соңыннан белербез.

(*Хайваннар кереп китә куян кала үз өе* янында)

*Куян:* Кәефем дә юк бүген, яңгыр да явып тора,

Койрыклы да буласым килә бит,

Берәрсенә генә кушармын әле койрык алып кайтырга.

*(юлдан аю килә)*

*Куян:* Аю бабай, койрык алырга барасынмы син?

*Аю:* Әйе, әйе, барам шул, койрык өләшәләр диләр бит, барып карыйм әле.

*Куян:* Карале аю бабай,

Авыр түгелдер койрык алай,

Алчы миңа бер матурны,

Рәхмәтле булырмын аю бабай!

*Аю:* Әгәр дә онытмасам алып кайтырмын, авыр эшмени алай.

*(аю китә, куян кул болгап кала)*

*Куян:* Аю бабай картарган,

Зихене дә таралган,

Онытыр үз вәгдәсен.

Аннан табар хәйләсен....(эх)

Тагын берәрсенә әйтми булмас...

*(Бүре килә)*

*Куян:* Исәнме бүре абзый...

Карт имән янына юл тоттынмы бүре абзый?

Миңа да берәр матур койрык алып кайта алмасыннмы икән ә?

*Бүре:*

Әгәр дә артык калса, барсына да җитәрлек булса, берәрне алып кайтырмын!

(бүре китә)

*Куян*: Ииии, юкка гына әрәм иттем сүз,

Буре бит ул туймас күз.

Алып бетерләр, берәү дә калмас,

Аннан алса да бирмәс....

Ярый башка берәүгә әйтеп карыйм әле.

Әхәәәәәә, әнә, әнә, хәйлә капчыгы килә...

Апакаем төлке, бу эш бер дә түгел көлке,

Үзем бара алмадым, койрыксыз калырмын дип куркам,

Алып кайтмассынмы берәр койрык.

*Төлке:* Куян дустым, борчылма,

Алып кайтырмын бер матур койрык,

Тунынңа килешле, матур, йомшак булыр,

Бер дә борчыылма алай.

Миннән шикләнмә дускай!

*(Төлке китә)*

Музыка куян кишерләр җыя җырлый җырлый

Шаяра әле күбәләк....

*(Хайваннар музыка астында чыгып, алмагачны әйләндереп куялар анда койрыклар, барсы да үзенә яраклы койрык ала, башка хйваннар да бар.*

*Койрыкларын тагып бтергәч, сокланып бииләр)*

*Төлке:* Ягез, әле, барыгыз да койрыклы булдымы?

*Куян:* (өеннән чыгып карап тора, урман ягына, аю килә)

Исәнме аю бабай, бик армадыңмы алай?

Койрык алып кайттыңмы миңа?

*Аю:* И куян, куркак куян, алып кайтмадым сиңа койрык,

Үзеңә барырга иде, койрык алырга иде...

Арып- талып барып, озак чират торып,

Үземә дә нинди кыска гына койрык алдым...

*(Куян күзләрен ышкый- ышкый җылар кала, урман юлыннан бүре килә)*

*Куян:* бүре абзый, миңа дигән койрыкны бир зинһар!

*Бүре:* кая сиңа койрык, үземә дә көчкә эләктерлем, кит юлымнан!

*(юлдан төлке килә)*

*Куян:* Төлке апакай, матур апакай, миңа да койрык алып кайтмадыңмы?

*Төлке:* Карале , кара монда, койрыгым минем , я ничек, матурмы? Үзе йомшак, үзе матур, ай- йай. Мондый койрык миндә генә! Ә сиңа койрык калмады!

*( Шул арады эт белән песи уртага чыгалар, талаша башлыйлар)*

*Песи:* минем койрыгым матур, синеке кебек түгел, фу, нинди койрык бу?

*Эт:* минем койрык матуррак, мактанма алай, барыбер минеке матуррак!

*(Сугыша башлыйлар, койрыкларына тотынышып әйләнәләр, шунда бер кечкенә генә койрык кисәге очып килеп тошә, куян моны күреп ала да, үзенә койрык итеп тага)*

*Куян:* Минә бит ул, миңа дигән, минем матур койрыгым, нинди матур койрык!

*Автор:* Менә шушы көннән алып эт белән песи бер – берсенә үч итеп әле дә булса талашып яшиләр ди.

*(барсы бергә чыгып биилəр )*














Сыйла
Угости
Сорап ал